**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссиянең персональ составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 29 апрелендәге ПУ-179 номерлы, 2009 елның 5 мартындагы ПУ-123 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-212 номерлы, 2009 елның 22 июнендәге ПУ-343 номерлы, 2010 елның 19 маендагы ПУ-330 номерлы, 2010 елның 11 ноябрендәге ПУ-742 номерлы, 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-896 номерлы, 2011 елның 26 мартындагы ПУ-158 номерлы, 2011 елның 19 маендагы ПУ-266 номерлы, 2011 елның 15 августындагы ПУ-504 номерлы, 2012 елның 24 гыйнварындагы ПУ-42 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-125 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-459 номерлы, 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2012 елның 10 ноябрендәге ПУ-937 номерлы, 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 29 декабрендәге ПУ-1183 номерлы, 2016 елның 11 мартындагы ПУ-237 номерлы, 2016 елның 22 августындагы ПУ-715 номерлы, 2018 елның 8 маендагы ПУ-365 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы һәм 2019 елның 9 октябрендәге ПУ-614 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссиянең (алга таба – Комиссия) персональ составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.Т. Борһановны, А.В. Мәүликовны, Р.З. Тимерҗановны, Г.Л. Удачинаны, Д.Г. Хәмитовны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Волынец Ирина Владимировнаны – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне (килешү буенча);

Гәрәев Марат Мәсгут улын – Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгын (килешү буенча);

Демидов Виктор Николаевичны – Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспекторны (килешү буенча);

Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

Хвостиков Игорь Владимировичны – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзасы Э.Д. Хиялиевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 19 декабрь
№ ПУ-856